ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2025 с.Старое Дрожжаное №561

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.10.2018 N 965, 29.12.2018 N 1262, 06.05.2019 N 380, 11.07.2019 N 565, 28.08.2019 N 714, 02.11.2019 N 1008, 30.12.2019 N 1278, 16.04.2020 N 294, 21.05.2020 N 413, 01.09.2020 N 772, 23.10.2020 N 954, 26.07.2021 N 645, 06.09.2021 N 821, 29.10.2021 N 1021, 30.10.2021 № 1030, 15.06.2022 № 566, 22.09.2022 № 1027, 24.06.2024 № 454, 25.09.2024 № 830, 30.12.2024 № 1273, 12.03.2025 № 149, 21.04.2025 № 252, 24.09.2025 № 732 ред.) карарларының гамәлдә булуын түбәндәге хезмәт өчен түләү шартларына таратырга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең, белгечләренең һәм җитәкчеләрнең гомумтармак вазыйфалары, мәдәният, сәнгать һәм кинематографиянең гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү

шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 30 апрелендәге 136 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов